КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2021 ел, 16 декабрь

г.Казань

№ 1240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «уздыруга» сүзләреннән соң «, Татарстан АССРда туган һәм яшәгән, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларны эзләү эшләрен башкаруга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «уздыруга» сүзләреннән соң «, Татарстан АССРда туган һәм яшәгән, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларны эзләү эшләрен башкаруга» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «уздыруга» сүзләреннән соң «, Татарстан АССРда туган һәм яшәгән, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларны эзләү эшләрен башкаруга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга– субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Татарстан АССРда туган һәм яшәгән, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларын эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булып тормаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – шул ук эзлеклелектә –проектлар, чаралар, эшләр башкару, субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Эшләрне башкаручы коммерцияле булмаган оешмаларга субсидияләр бирү әлеге чыгымнарны каплау максатларында гамәлгә ашырыла.»;

4 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның өченче абзацында «чаралар уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

18 пунктта:

бишенче абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацта татар текстында «оештыру һәм уздыру» сүзләреннән соң «, эшләр башкару» сүзләрен өстәргә;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия бирүнең нәтиҗәләре:

а) проектларны гамәлгә ашыру кысаларында:

заявка нигезендә гамәлгә ашырылган проектлар саны – кимендә бер берәмлек;

фактта җәлеп ителгән максатчан аудитория – кимендә 100 кеше;

б) заявка нигезендә гамәлгә ашырылган чараларны оештыру һәм уздыру кысаларында:

сәнгати-техник параметрларга туры килә торган, гамәлгә ашырылган чаралар саны – кимендә бер чара;

катнашучылар саны – кимендә 100 кеше;

башкаручылар саны – кимендә бер кеше яки бер оешма;

в) эшләр башкару кысаларында:

Татарстан АССРның сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган халкының кимендә бер кешесен эзләү;

Татарстан АССРда туган, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларның кимендә берсен эзләү.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 25 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү сроклары субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 декабреннән дә соңрак билгеләнә алмый.»;

әлеге Тәртипкә кушымтаның нумерация башисемендә татар текстында «уздыруга» сүзләреннән соң «, Татарстан АССРда туган һәм яшәгән, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган затларны эзләү эшләрен башкаруга» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин